СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 12-25 «19» апрель 2018 ел

Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү буенча комиссияләр турында»2010 елның 25 августындагы ПУ - 569 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2014 елның 18 ноябрендәге № 9-34 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15.6 пунктчасын өстәргә:

«15.6. Әлеге Нигезләмәнең 15.1, 15.3 һәм 15.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләр үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

а) әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм

хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 22, 23.3, 24.1 пунктлары яисә башка карар кабул итү өчен күрсәтмәләр.»

2. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе — А.П. Иванов